**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ**

КАРАР

**№ 18 Уруссу штп « 19 » 10 2015 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының**
**"Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 21.11.2014 ел**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 21.11.2014 ел карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 1 пунктчада:

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар. Ставка салым түләүче сайлавы буенча бер гаражга яисә машина-урынга карата билгеләнә";

б) 4 пунктчада:

икенче һәм өченче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 6 пунктчаны өстәргә:

«6) 2015 елда - 1,2 процент, 2016 елда - 1,5 процент, 2017 елда - 1,8 процент, 2018 елда - 2 процент һәм аннан соңгы елларда:

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата;

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 3 пункт белән тулыландырырга:

«3. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатирга милек хокукына ия физик затларга ташлама билгеләргә, бу фатирның гомуми мәйданындагы утыз квадрат метр салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә була.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир гомуми уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектәге һәр катнашучы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләп чыгарылган салым суммасыннан артып китә алмый ".

1.3. 3, 4 пунктларны 4, 5 пунктлар дип санарга.

2. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015елның 10 сентябрендәге 14 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар административ бинаның мәгълүмат стендында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatar.ru веб-адресы буенча урнаштырылгач үз көченә керә

һәм 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.http://jutaza.tatar.ru

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы башлыгы -
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Советы рәисе Р.М. Нуриев